КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 17 сентябрь г.Казань № 709

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен диспансерлаштыруны оештыруга хезмәт күрсәтүләр күләмнәре нормативларын һәм норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен диспансерлаштыруны оештыруга хезмәт күрсәтүләр күләмнәре нормативларын;

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен диспансерлаштыруны оештыруга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен диспансер-лаштыруны оештыруга хезмәт күрсәтүләр күләмнәре нормативларын һәм норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 7 сентябрь, 743 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 17 сентябрь, 709 нчы
карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен диспансерлаштыруны оештыруга хезмәт күрсәтүләр күләмнәре нормативлары

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү күләме нормативы, кеше | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Яше 40 ка кадәр булган ир-ат җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация | 777 | 777 | 777 |
| Яше 40 тан арткан ир-ат җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация | 730 | 730 | 730 |
| Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация | 1 982 | 1 982 | 1 982 |
| Яше 40 тан арткан, маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация | 1 059 | 1 059 | 1 059 |
| Яше 40 тан арткан, маммография үтмәүче хатын-кыз җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация | 536 | 536 | 536 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 17 сентябрь, 709 нчы
карары белән расланды

# 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен диспансерлаштыруны оештыруга норматив чыгымнар

| Норматив чыгымнар исеме | Бер кешегә норматив чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Яше 40 ка кадәр булган ир-ат җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация оештыру чыгымнары | 16 027,85 | 16 668,94 | 17 335,7 |
| Яше 40 тан арткан ир-ат җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация оештыру чыгымнары | 17 263,99 | 17 954,55 | 18 672,74 |
| Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация оештыру чыгымнары | 15 915,17 | 16 551,77 | 17 213,83 |
| Яше 40 тан арткан, маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация оештыру чыгымнары | 17 593,81 | 18 297,58 | 19 029,5 |
| Яше 40 тан арткан, маммография үтмәүче хатын-кыз җенесендәге дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация оештыру чыгымнары | 17 151,37 | 17 837,43 | 18 550,93 |

_______________________